**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ГОРОДА ЛАИШЕВО**

ул. Коммунальная,
д.3,г.Лаишево,422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘРЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Коммунальная ур., 3 нче йорт,
Лаеш ш.,422610

тел: 8-(84378) -2-57-77, факс: 8-(84378) -2-50-62, e-mail:Gorod.La@tatar.ru

**2022 елның«26 » апреле** **35 номер**

# КАРАР

Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, О.Кошевой урамы, 36А йорт адрес буенча урнашкан, кадастр номеры 16:24:170140:195 булган җир кишәрлеген яңадан бүлү юлы белән территорияне ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында.

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре” муниципаль берәмлеге уставы белән, кешенең уңайлы тормыш шартларына хокукларын,җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларына хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында,Вәлиуллина Г. Б. гаризасы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, О.Кошевой урамы, 36А йорт адрес буенча урнашкан, кадастр номеры 16:24:170140:195 булган җир кишәрлеген яңадан бүлү юлы белән территорияне ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә :

2.1 Үткәрү датасы һәм вакыты-2022 елның 27 мае 14.00 сәгатьтә.

2.2 Үткәрү урыны-Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре Башкарма комитеты бинасы, адресы: 422610, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, Коммунальная ур., 3.

2.3 Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, О.Кошевой урамы, 36А йорт адрес буенча урнашкан, кадастр номеры 16:24:170140:195 булган җир кишәрлеген яңадан бүлү юлы белән территорияне ызанлау проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне, халык алдында чыгыш ясау хокукы белән гаризаларны Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, Коммунальная ур., 3

нче йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре Башкарма Комитетына тапшырырга мөмкин.

2.4 Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар 2022 елның 26 маена кадәр кабул ителә.

3. Әлеге карарны "Кама ягы"(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәренең махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче В.А. Арефьев